РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АКСУНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13 октябрь 2021 ел № 28-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә , Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советы

РЕШИЛ:

1. 2018 елның 14 июлендәге 54-2 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» (12.05.2020 ел, № 87-1, 19.08.2020 ел, № 93-1, 20.10.2020 ел, № 4-2, 15.09.2021 ел, № 28-1 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 статья:

10 пунктның 4 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне, бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслы һәм максатчан характерда куллануны тәэмин итә;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Аксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов